**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «01» апреленнән № 89

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү хакында» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2023 елның 14 февралендәге 41 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү хакында» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 8 өлеше, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 һәм 78 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге ФЗ-544 номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 2 пунктының икенче һәм дүртенче абзацлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 28 июлендәге 884 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы турында нигезләмәнең 4 пунктындагы 4.2.21 пунктчасы, «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 02 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2025 елның 04 мартындагы 171 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында

«Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү хакында» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2023 елның 14 февралендәге 41 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү хакында» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 24 маендагы 149 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге» 2.6. бүлегенең 2.6.1 пунктының 2 - 14 (2 һәм 14 не кертеп) абзацлары чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан тапшырыла торган документларга карата кагылмый.

1.2. 2.6. бүлегенең 2.6.1 пунктының 16 абзацына түбәндәге эчтәлектәге текст өстәргә:

«Чит ил гражданнары, түбәндәге документларны күрсәтәләр:

бала туу турында таныклык күчермәсе;

паспорт күчермәсе;

яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов